Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге составына керүче Күзкәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге составына керүче Күзкәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кузкәй авыл җирлегенең Кузкәй авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар истәлегенә мемориал әзерләү һәм урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Пионер урамында юл төзелеше буенча эшләр башкару, вак таш, асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре күрсәтү)»;

2) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 29 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Күзкәй авылында гражданнар җыены карарына:

«- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кузкәй авыл җирлегенең Кузкәй авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар истәлегенә мемориал әзерләү һәм урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Пионер урамында юл төзелеше буенча эшләр башкару, вак таш, асфальт ватыклары сатып алу, махсус техника хезмәтләре күрсәтү)».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Күзкәй авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Күзкәй авыл җирлеге Башлыгы Э.Р. Гәрәев